**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«20» июль, 2023 ел

№ 510

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2023 елның икенче яртыеллыгына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен раслау турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Россия Федерациясе Торак коды, 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен билгеләү методикасы һәм, Методиканы файдаланып, күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителергә тиешле салым салынырга тиешле мөлкәт бәясен билгеләү методикасы нигезендә, Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлегенең 2023 елның 21 февралендәге 63 номерлы «Коммерция булмаган партнерлык»ның хатына таянып Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен максималь күрсәткечләр билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен - 2 557 500 сум

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 3 255 000 сум

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 4 185 000 сум

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 5 580 000 сум

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен - 6 975 000 сум

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 6 975 000 сум

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен - 9 765 000 сум

1.2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 33 510,22 сум

1.2.2. Ике кешелек гаилә өчен - 21 324,69 сум

1.2.3. Өч кешелек һәм аннан күбрәк кеше өчен - 18 278,30 сум

2. Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән максималь күләмнәрне наем шартнамәсе буенча торак урын бирелүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда файдаланырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе — В.И. Никитин